| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| --- | --- |
| СОВЕТ ЛЕШЕВ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛӘШӘҮ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

24 сентябрь 2018ел № 16

Ләшәү-Тамак авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Ләшәү-Тамак авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә Сарман муниципаль районы Ләшәү-Тамак авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ.:

1. Бу мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

"2019 елда Ләшәү-Тамак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 250 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?:

1).Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, әлеге кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Ләшәү Тамак, Сарайлы, Дүсем, Түбән Ләшәү торак пунктларында яктырткычлар алыштыру һәм урнаштыру;

- махсус техника өчен ян өемнәре сатып алу ; ;

- МТЗ-82 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, хезмәт хакы түләү);

- Ләшәү Тамак т. п., Дүсем авылында зур агачларны кисү;

- Сарайлы авылында һәйкәл территориясен төзекләндерү ;

- Сарайлы, Түбән Ләшәү авылларына үлән чабу өчен триммер сатып алу;

2). Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә, шул исәптән җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- кыш көне Ләшәү Тамак, Сарайлы, Дүсем, Түбән Ләшәү авылларында җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту.

3). Җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру, шул исәптән:

- Җиңү көне, Сабантуй, өлкәннәр көне бәйрәмнәре үткәрү өчен бүләкләр, алу;

- Сарайлы авылына балалар мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру.

4). Җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру, шул исәптән:

- Дүсем авылы зираты территориясен киртәләп алу өчен материаллар сатып алу;

- Ләшәү Тамак авылы ритуаль кирәк-яракларны саклау өчен будка ясау, материаллар сатып алу.

5). Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү, шул исәптән:

- Сарайлы авылына янгын гидранты, янгынга каршы башка җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру.

ЮК ӘЛЕ".

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ләшәү-Тамак Башлыгы
авыл җирлеге башлыгы: И. З. Хабибуллин